**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

Чернышевский урамы, 23нчейортЛаешш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34

e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

2021елның 17 феврале 325 номер

# КАРАР

**«2020-2024 елларга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитетының 2020елның 3 мартындагы 346 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

"Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында"2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, шулай ук Лаеш муниципаль районының кече һәм урта эшкуарлык субъектларына ярдәм итү максатларында карар бирәм:

1. «2020-2024 елларга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитетының 2020елның 3 мартындагы 346 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә, кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http:/pravo.tatarstan.ru адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http:/laishevo.tatarstan.ru.веб адресы буенча бастырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

.

Җитәкче А.А. Новиков

*Татарстан Республикасы*
*Лаеш муниципаль районы*
*Башкарма комитетының*
*2021 елның 17» февралендәге*
*325 номерлы карарына*
*кушымта*

**«2020-2024 елларга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү программасын раслау турында» 2020елның 03 мартындагы 346 номерлы Татарстан Республикасы башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү**

1) 7 пунктның 10 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр (алга таба - сатып алу) - әлеге Федераль законда билгеләнгән тәртиптә заказчы тарафыннан гамәлгә ашырыла торган һәм дәүләт яисә муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итүгә юнәлдерелгән гамәлләр җыелмасы. Сатып алу тәэмин итүче (подрядчы, башкаручы) билгеләмәсеннән башлана һәм контракт яклары тарафыннан йөкләмәләрне үтәү белән тәмамлана. Әлеге Федераль закон нигезендә сатып алуны гамәлгә ашыру турында хәбәрнамә урнаштыру яки җиткерүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләүдә катнашырга чакыру юнәлеше каралмаган очракта, сатып алу контракт төзүдән башлана һәм контракт яклары тарафыннан йөкләмәләрне үтәү белән тәмамлана.;